КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 7 май г.Казань № 310

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 28 сентябрь, 919 нчы карары белән расланган Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, аларны карап тотуга, саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт (контроле) күзәтчелеге турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, аларны карап тотуга, саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт (контроле) күзәтчелеге турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 28 сентябрь, 919 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1334 нче, 2023 ел, 13 июнь, 713 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, аларны карап тотуга, саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт (контроле) күзәтчелеге турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметы булып юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар һәм гражданнар (алга таба - контрольдә тотыла торган затлар) тарафыннан төбәк әһәмиятенәге, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына,

ачыкланган мәдәни мирас объектларына һәм «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба - 73-ФЗ номерлы Федераль закон) 3 статьясы нигезендә мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектларга, төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларын саклау зоналарына, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын саклау зоналарына, төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларының яклау зоналарына, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының яклау зоналарына, шулай ук 73-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителә торган башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында билгеләнгән тарихи җирлекләргә (исемлекләре 73-ФЗ номерлы Федераль законның 91 статьясындагы 1 пункты нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектларыннан тыш) карата мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендәге мәҗбүри таләпләрне үтәү тора, түбәндәгеләрне кертеп:

мәдәни мирас объектларының милекчеләренең яисә башка законлы хуҗаларының саклау йөкләмәләре таләпләре;

мәдәни мирас объектын тотуга һәм алардан файдалануга таләпләр, мәдәни мирас объектын саклап калуга таләпләр, мәдәни мирас объектыннан файдалана алуны тәэмин итүгә таләпләр;

мәдәни мирас объектын саклау зоналары территорияләре чикләрендә, истәлекле урын территориясе чикләрендә, тарихи җирлек территориясе чикләрендә һәм шушы территорияләр өчен билгеләнгән җирләрдән файдалануның махсус режимнарын исәпкә алып, шәһәр төзелеше регламентларына таләпләр;

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы, җирле үзидарә органнары тарафыннан мәдәни мирас объектларын саклау турындагы законнар нигезендә бирелгән рөхсәт документларындагы таләпләр;

мәдәни мирас объектларын саклап калу эшләрен уздыруга таләпләр, шул исәптән эшләрнең килештерелгән проект документациясенә һәм аларны саклау эшләрен башкаруга рөхсәткә туры килүе турында;

мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә, мәдәни мирас объектын саклау зоналары территорияләре чикләрендә, мәдәни мирас объектын саклау зоналары территорияләре чикләрендә, истәлекле урын территориясе чикләрендә, тарихи җирлек территориясе чикләрендә эшчәнлекне гамәлгә ашыруга таләпләр яисә чикләрендә 73-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән археологик мирас объекты урнашкан җир кишәрлегеннән, су объектыннан яисә аның өлешеннән файдалануның махсус режимы таләпләре;

социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итүгә карата таләпләр;

төбәк әһәмиятендәге яисә җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, 73-ФЗ номерлы Федераль законның 561 статьясында каралган ачыкланган мәдәни мирас объектлары булып торучы күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләрен уздыруга карата таләпләр;

Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектының, ачыкланган мәдәни мирас объектының, шулай ук 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән эзләү, проект, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләре, урманнардан файдалану эшләре һәм башка эшләр барышында табылган 73-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы нигезендә мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектның сакланышын тәэмин итү чаралары, шул исәптән мәдәни мирас объектларын саклап калу эшләрен башкаруга капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә, капиталь ремонтлауга проект документациясендә каралган чаралар.»;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Мәдәни мирас объектларына зыян китерү, мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә мәҗбүри таләпләр бозылу куркынычын бәяләү максатларында планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасы төрен үткәрү һәм сайлау турында карар кабул иткәндә түбәндәге куркыныч индикаторлары кулланыла:

мәдәни мирас объектына зыян китерү куркынычы булган контрольдә тотыла торган затның гамәлләре (гамәл кылмавы);

мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә, аларның яклау зоналарында һәм саклау зоналарында мәҗбүри таләпләрне бозуга алып баручы контрольдә тотыла торган затның гамәлләре (гамәл кылмавы);

мәдәни мирас объектын саклау зонасында һәм (яисә) төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты, ачыкланган мәдәни мирас объекты территориясендә һәм (яисә) төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты, ачыкланган мәдәни мирас объекты, тарихи кыйммәткә ия шәһәр төзүче объект урнашкан җир кишәрлеге чикләрендә һәм (яисә) күрсәтелгән объектлар биналарында мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен уздыруга рөхсәт һәм (яисә) 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән тикшеренү, проект, җир, төзелеш, мелиоратив, хуҗалык эшләрен, урманнардан файдалану һәм башка эшләр башкару проектында мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү турында килештерелгән бүлек яисә мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү проекты йә башкарыла торган эшләрнең мәдәни мирас объектына йогынтысын бәяләүне үз эченә алган коткару археологик кыр эшләрен уздыру планы, тарихи җирлекнең саклау предметына туры килү-килмәү өчен төзелеш, ремонт эшләре үткәрү турында проект документациясе (эскиз проекты) булмаган очракта төзелеш техникасы, төзелеш инструментлары, һәм (яисә) төзелеш материаллары, һәм (яисә) төзелеш чүп-чары булу;

Әлеге объектның элек төзелгән техник халәте актына карата төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектының, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектының, ачыкланган мәдәни мирас объектының 73-ФЗ номерлы Федераль законның 33 статьясындагы 2 пунктының 14 пунктчасы нигезендә мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы чараларын үткәрү кысаларында ачыкланган техник торышы начараю.

Мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары ачыкланганда зыян (зарар) китерү куркынычы дәрәҗәсен характерлаучы, Россия Федерациясе законнары

таләпләрен үтәп, аларның дөреслеген тәэмин итүче теләсә нинди чыганаклардан, шул исәптән профилактик чаралар, контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрү барышында, рөхсәт эшчәнлеге кысаларында вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан, гражданнарга һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр оешмаларына күрсәтү нәтиҗәләре буенча, контрольдә тотыла торган затлар, башка гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләреннән, массакүләм мәгълүмат чаралары хәбәрләреннән алынган белешмәләр, шулай ук мәгълүмат ресурсларында булган, шул исәптән маркировканы, күзәтелүне, исәпкә алуны, мәгълүматны автомат теркәүне тәэмин итүче белешмәләр һәм контроль объектлары турында башка белешмәләр кулланылырга мөмкин.»;

38 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«38. Тикшерүләр программасы дәүләт органы тарафыннан түбәндәгеләр нигезендә төзелә:

дәүләт органы биргән мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен башкаруга рөхсәт;

мәдәни мирас объекты милекчесенең яисә мәдәни мирас объектының башка законлы хуҗасының саклау йөкләмәсе белән билгеләнгән мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен уздыру срогы узу (чоры тәмамлану) (алга таба тиешенчә - саклау йөкләмәсе, мәдәни мирас объектының  хокук иясе);

73-ФЗ номерлы Федераль законның 561 статьясында каралган мәдәни мирас объекты булган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләре башлану турында хәбәрнамә.

Тәгаен бер мәдәни мирас объектына карата әлеге пунктның икенче, өченче абзацларында күрсәтелгән вакыйгаларның берсе барлыкка килгәндә инспектор мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен башкаруга рөхсәт бирелгән көннән, мәдәни мирас объектын саклау йөкләмәсендә билгеләнгән эшләр башкару срогы тәмамланган (чоры узган) көннән алып өч эш көне эчендә тикшерү программасын әзерли һәм аны дәүләт органы җитәкчесенә раслауга тәкъдим итә.

Әлеге пунктның дүртенче абзацында күрсәтелгән вакыйга барлыкка килгәндә, дәүләт органы тарафыннан, 73-ФЗ номерлы Федераль законның 561 статьясындагы 8 пунктында каралган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләрен башкару башлануы турында хәбәрнамә алган көннән соң җиде эш көненнән дә соңга калмыйча, дәүләт органы җитәкчесе тарафыннан раслана торган тикшерүләр программасы төзелә.»;

40 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«40. Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын, ачыкланган мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен уздыруга бирелгән рөхсәт нигезендә контрольдә тотыла торган зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тоткан контроль (күзәтчелек) чарасы гамәлгә ашырыла (инспекция визиты, рейд тикшерүе, документар тикшерү, күчмә тикшерү).

Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын,  җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын, саклау йөкләмәсендә билгеләнгән ачыкланган мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен башкару срогы тәмамлану  (чоры узу) нигезендә контрольдә тотыла торган зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тоткан

контроль (күзәтчелек) чарасы да  (инспекция визиты, рейд тикшерүе, документар тикшерү, күчмә тикшерү), контрольдә тотыла торган зат белән үзара хезмәттәшлек итмичә контроль (күзәтчелек) чарасы да (мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү, күчмә тикшерү) үткәрелергә мөмкин.

төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты, 73-ФЗ номерлы Федераль законның 561 статьясында каралган ачыкланган мәдәни мирас объекты булган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләре башлану турында хәбәрнамә нигезендә контрольдә тотыла торган зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тоткан түбәндәге контроль (күзәтчелек) чараларының берсе гамәлгә ашырыла (инспекция визиты, рейд тикшерүе, документар тикшерү, күчмә тикшерү).»;

51 пунктның унберенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин